*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен**
**татар теленнән республика олимпиадасының**
**муниципаль туры биремнәре**
**2025-2026 нчы уку елы**
**7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 64**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Җөмләдәге аваз чиратлашуы дөрес күрсәтелгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Күке җитене бизи язгы урманны, матурлыгы белән карашыбызны җәлеп итә.(М. Рафиков)*
1) җитене
2) язгы
3) матурлыгы
4) карашыбызны

2. Яңгырау тартык авазлар гына кергән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) шәһәребез
2) дөньядагы
3) авылдашлар
4) балакайлар

3. Антоним сүзләр кулланылган җөмләне билгеләгез. (**2 балл**)
1) Ак күл көзге кебек шома боз белән капланган иде.
2) Алар, кәшәкә сыман таякларын алып, күлгә таба йөгерделәр.
3) Бозлар арасында, бер батып, бер калкып, кунак кызыбызның башы гына күренгәли иде.
4) Абдулла, әкрен генә артка таба шуып, кызны боз өстенә тартып та чыгарды.

4. Эчтәлегенә карап, җөмләнең ахырын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Дөнья шулай шул ул, балам, үзең егылсаң да еламыйсың,......*
1) бары тик көләсең.
2) торасың да китәсең.
3) авыртуга да түзәсең.
4) бу – яхшы күренеш.

5. Орфографик хатасы булган сүзне табыгыз **(2 балл).**
1) нигезсез
2) алдыңгы
3) мәхәббәт
4) каһарман

6. Сүзтезмәнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Алдан бишенче*
1) фигыльле сан сүзтезмә
2) санлы рәвеш сүзтезмә
3) исемле сан сүзтезмә
4) санлы исем сүзтезмә

7. Ясалма сүз кулланылган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Батыр үз халкын яклый.
2) Батырга яра да килешә.
3) Батырлыкта матурлык.
4) Батыр кеше бакыр өзәр.

8. Тартым белән төрләнгән исемнәр рәтен билгеләгез. **(2 балл)**
1) кош, кошчык, кошлар
2) алма, алманың, алмага
3) әнием, китабы, хатларың
4) дәфтәрләр, чишмәләр, күлләр

9. Җөмләдә куелырга тиешле тыныш билгесен билгеләгез. **(2 балл)**
*Кырым халкы кар бураннарын  суыкларны белми.*
1) өтер
2) ике нокта
3) сызык
4) нокта

10. Җөмләдә аерып бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге булуын билгеләгез. **(2 балл)**
*Ул кичне авылдан аеруча **күңелсез** хәбәр килде.*
1) аергыч
2) хәл
3) хәбәр
4) тәмамлык

## II. Теоретик бирем.

Искергән сүзләр турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. **(8 балл)**

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Мәкальләрнең ахырын уйлап языгыз. **(5 балл)**

1) *Өең кысан булса да,* ________________________________________________.
2) *Яхшы тел –* ______________________________________________________.
3) *Сөйдергән дә – тел,*______________________________________________.
4) *Баканың да* ______________________________________________________ .
5) *Өйрәнгән*__________________________________________________________.

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Тексттагы <... > тамгасы урынына тиешле тыныш билгеләрен куегыз. **(7 балл)**

Март ахыры якынлашкач <... > беренче зур яңалык шул булды <... > кычыткан күбәләге оча башлады. Кирпеч төсле кызыл күбәләк. Шул кызыл өстендә вак кара таплар күренә. Юка канатлары читеннән кара кайма киткән <... > ә каймага зәңгәр таплар тезелгән. Күбәләк суыкны агач ярыгында уздырган һәм яз җиткәч уянган.

Бераздан үрмәкүчләр уянды <... > кайберләре кар өстендә сәяхәт итә башлады. Иртән кояш күренә <... > үрмәкүч терелә <... > кичен суыта <... > ул тагы үлеп куя. *(Г. Хәсәнов*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Татлы тәм бар ипекәйдә.
Төш....ндем мин яши-яши:
Кеше аңа үз ө....ндә
Сөенечен кушып ашый.
Ачы тәм бар ипекәйдә.

Карусыз гом...р юлдашы:
Шуның өчен аңа кеше
Кө....нечен кушып ашый. (*Р. Зәйдулла*)

3. *Ачы тәм бар ипекәйдә.* җөмләсенә синтаксик анализ ясагыз. (**4 балл**)

___

___

___

4. Шигырьдән антоним парларны күчереп языгыз, сүзләрнең кайсы сүз төркемнәренә каравын билгеләгез. (**4 балл**)

___

5. Шигырьдән үткән заман хикәя фигыльне табып языгыз, морфологик анализ ясагыз. **(3 балл)**

___

___

6. Сөйләм теленә хас сүзне күчереп алыгыз. **(2 балл)**

___

7. “Икмәк кадере” темасына 8-9 җөмләдән торган инша языгыз. (**9 балл**)

___